КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 3 август г.Казань № 631

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 5 июнь, 416 нчы карары белән расланган Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 ел, 5 июнь, 416 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 19 июнь, 393 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибенә һәм шартларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«территорияне төзекләндерү элементлары, шул исәптән кече архитектура формалары, территорияне уңайлаштыруның состав өлеше буларак кулланыла торган

капиталь булмаган стандарт булмаган төзелмәләр һәм корылмалардан, реклама конструкцияләреннән тыш »;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«барлык төрдәге җылылык челтәрләре, урнаштыру өчен төзелешкә рөхсәт таләп ителми торган кайнар су белән тәэмин итү челтәрләрен кертеп».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин